КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 декабрь г.Казань № 1149

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2025 елларда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән расланган 2025 елда эш бирүче инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яки) тулы булмаган эш атнасы, эшне вакытлыча туктатып тору режимын кертү, оешманы бетерүгә яисә индивиудаль эшмәкәр эшчәнлеген туктатуга, оешма, индивиудаль эшмәкәр хезмәткәрләре санын яки штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән азат итү чараларын үткәрү турында карар кабул ителгән хезмәткәрләрнең хезмәте өчен өлешчә түләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2025 елларда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2022 ел, 23 март, 258 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 август, 846 нчы; 2022 ел, 14 сентябрь, 1001 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1488 нче;

2023 ел, 10 февраль, 129 нчы; 2023 ел, 8 июль, 802 нче; 2024 ел, 14 июнь, 426 нчы; 2025 ел, 27 октябрь, 865 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2025 елда эш бирүче инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яки) тулы булмаган эш атнасы, эшне вакытлыча туктатып тору режимын кертү, оешманы бетерүгә яисә индивиудаль эшмәкәр эшчәнлеген туктатуга, оешма, индивиудаль эшмәкәр хезмәткәрләре санын яки штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән азат итү чараларын үткәрү турында карар кабул ителгән хезмәткәрләрнең хезмәте өчен өлешчә түләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен эш бирүчеләргә субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктның унбишенче абзацында татар текстында «шартлары һәм тәртибе үтәлешен» сүзләреннән соң «, субсидия бирү турында килешү төзегән эш бирүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.1 пунктында каралган хисапларны һәм (яки) хисап документларын» сүзләрен өстәргә;

3.12 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

5.2 пунктның икенче абзацында «карау» сүзен «тикшерү» сүзенә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 27 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин